ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.01.2024 с.Старое Дрожжаное № 1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законна таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 27 маендагы 9/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең уңай яшәү шартларына, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны үткәрү инициаторы булып - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2022 елның 14 мартындагы 58-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы (25.12.2023 ред.) нигезендә гавами тыңлаулар үткәрү чоры: кызыксынган затларга аларны үткәрү турында хәбәр ителгәннән алып, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр - бер айдан да артык булмаган вакыт эчендә;

- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү вакыты: Кушкуак авылындагы торак пункт өчен - 2024 елның 29 гыйнварында - 09:00 сәгатьтән 10:00 сәгатькә кадәр; Хайбулдино авылындагы торак пункт өчен - 2024 елның 29 гыйнварында - 11:00 сәгатьтән 12:00 сәгатькә кадәр; Чуаш Чүпрәлесе авылындагы торак пункт өчен - 2024 елның 29 гыйнварында 14:00 сәгатьтән 15:00 сәгатькә кадәр;

- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү урыны: Кушкуак авылы торак пункты өчен - Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Кушкуак

авылы, Родник урамы, 1 нче торак йорт янында; Хайбулдино авылындагы торак пункт өчен - Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Хайбулдино авылы, Клуб урамы, 1 йорт, авыл клубында; Чуаш Чүпрәлесе авылындагы торак пункт өчен - Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Чуаш Чүпрәлесе авылы, Октябрь урамы, 21А йорт, мәдәният йортының тамаша залында;

- проект белән алдан танышу өчен экспозиция урнаштыру урыны: Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: https://drogganoye.tatarstan.ru/ «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә; Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлегендә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Үзәк урамы, 13;

- гавами тыңлауларда катнашучылар фикер алышкан мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрә ала торган адрес: 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Үзәк ур., 13 йорт, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге; 422485, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Чуаш Чүпрәлесе авылы, Октябрь ур., 21А йорт, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлеге Башкарма комитеты.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуваш-Чүпрәлесе авыл җирлеге Башкарма комитетына гамәлдәге законнар һәм әлеге карарның 3 пунктында билгеләнгән шартлар нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуваш-Чүпрәлесе авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар оештырырга һәм үткәрергә.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлегенең Генераль планы проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен әзерләү буенча эш төркеме составын кушымта нигезендә расларга.

6. Гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлегенең Генераль планы проектын, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм ахыргы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә җибәрергә.

7. Әлеге карарны «Туган як» район газетасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://drogganoye.tatarstan.ru/ «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше буенча җитәкче урынбасары Р.Р. Баһаутдиновка йөкләнә.

Чүпрәле муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Е. Ярухин

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башлыгының
2024 елның "16" гыйнвар 2024
1 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлегенең Генераль планы проектын тикшерү буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Мөхәммәтҗанов Р.И. | - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркеме рәисе (килешү буенча); |
| Фатхеев Ф.Р. | - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге баш белгече, эшче төркем секретаре (килештерү буенча); |

Эш төркеме әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Баһаветдинов Р.Р. | - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары (килештерү буенча); |
| Хәйруллин И.Р. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Хусаинов И.М. | - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм ТКХ бүлеге башлыгы (килештерү буенча); |
| Шуркин Ю.И. | - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм ТКХ бүлеге башлыгы (килештерү буенча); |
| Землемеров В.В. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш-Чүпрәлесе авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча). |